**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Арча 6 нчы номерлы урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе**

# Муса Җәлилгә багышланган “Тамчы шоу” интеллектуаль уены

Укытучы:
югары квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Газизова Эльмира Илгиз кызы

**Муса Җәлилгә багышланган “Тамчы шоу” интеллектуаль уены.**

Исәнмесез, диеп башлыйк әле,
Һәр очрашу шулай башлана.
Исәнмесез, диеп сүз башланса,
Күңелләрдә ныграк саклана.

Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, укучылар! Хәерле, имин көннәр сезгә!

Бүген 15 нче февраль – Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, татар халкының батыр улы, патриот шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне.

Муса Җәлил! Бу исем – гасырлар буена буыннан-буынга, телдән-телгә сөйләнәчәк легендар исем. Аның “Моабит дәфтәрләре” – кешенең рухи батырлыгына һәйкәл. Бу шигырьләр яшь буында җиңүләргә омтылыш булдыра.

Билгеләми гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык җитүе.
Бәлки, менә шушы үлем безгә
Мәңге бетмәс яшәү китерер?!

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне.
Йөзәү булса гомрең, син барсын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?

Шатландыра безне көн дә илнең
Бер-бер яңа уңышын ишетү;
Нинди зур көч читтә үз-үзеңне
Халкың белән бергә хис итү!

Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер
Ил гомеренең тик бер чаткысы,
Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан
Арта бары аның яктысы.

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы йөрәкне.
“Үлем” диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне.

Батыр үлә үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып,
Исмең калсын үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.

Ә хәзер, укучылар, герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган “Тамчы шоу” интеллектуаль уенын башлыйбыз. Уенда 6 мәктәп укучылары катнаша.

Укучылар, сәхнәдә әзерләнгән махсус урыннарга рәхим итегез!

***1 нче мәктәп командасының исеме –“Таң йолдызлары”;***

***2 нче мәктәп командасының исеме – “Маяк”;***

***5 нче мәктәп командасының исеме – “Чәчәкләр”;***

***6 нчы мәктәп командасының исеме – “Кызыл ромашка”;***

***7 нче мәктәп командасының исеме – “Хыял”;***

***Лесхоз мәктәбе командасының исеме – “Ромашкалар”.***

Бүгенге уенда командалар чыгышын мәртәбәле жюри бәяли. Танышыйк әле:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

_________________________________________________________________

Уеныбызны башлыйбыз! Сәламләү өчен сүзне командаларга бирәбез.

Уеныбыз 6 турдан торачак. Уңышлар сезгә!

**I тур. "Батыр берне, белемле меңне егар".**

Әлеге турда мин сезгә сораулар бирәм. Сораулар М.Җәлилнең тормыш юлы буенча булачак.

Командаларга мин сорауны әйткәннән соң, һәр команда катнашучылары әлеге сорауга җавапны кәгазьгә яза. Сораулар саны 10 булачак. Кәгазьгә язган җавап вариантын күрсәтеп, аларны әйтә барасыз, алты команданың да җавабы тыңланачак, әгәр җаваплар дөрес булса, барлык командаларга да баллар куелачак. Нәтиҗәдә, һәр команда ничә сорауга дөрес җавап бирсә, шулкадәр балл җыя алачак.

1.**Муса Җәлил кайда туа**?

Муса Җәлил Оренбург губернасы Шарлык районы Мостафа авылында туа.

2.**Муса Җәлил Оренбургта нинди мәдрәсәдә белем ала?**

Муса Җәлил Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала.

3.**Муса Җәлилнең беренче җыентыгы кайчан чыга?**

Муса Җәлилнең беренче җыентыгы 1925 нче елда «Барабыз» исеме астында чыга.

4.**Муса Җәлил сугышка китәр алдыннан нинди шәһәрдә политҗитәкчеләр курсында укый?**

1941 нче елда Минзәлә шәһәренең педагогик көллиятендә политҗитәкчеләр курсында укый.

5.**Сугышта Муса Җәлил эшләгән фронт газетасының исеме ничек дип атала?**

Муса Җәлил 1942 нче елның гыйнварында Волхов фронтының икенче удар армиясенә эләгә. «Отвага» газетасының корреспонденты була.

6. **1942 нче елда Муса Җәлилнең нинди җыентыгы чыга?**

1942 нче елда Казанда «Тупчы анты» җыентыгы чыга.

7.**Сугыштан соң Муса Җәлилнең шигырьләре беренче тапкыр кайда басыла?**

1953 нче елның 25 нче апрелендә «Литературная газета» битләрендә Моабит циклыннан 6 шигыре басылып чыга.

8. **«Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәләре хәзер кайда саклана?**

Атаклы «Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәләре 1983 нче елдан Казанда Муса Җәлилнең музей-квартирасында саклана.

9. **Муса Җәлилнең Казандагы һәйкәле авторы һәм ачылу елы.**

1966 нчы елда Муса Җәлилнең 60 еллыгына Казанда һәйкәл ачыла. Авторы – Владимир Ефимович Цигаль.

10. **«Хөкем алдыннан» картинасының авторы.**

Харис Якупов.

**II тур.**

**Экранда һәр команда өчен аерым Муса Җәлилнең портреты яки аңа багышланган картина күрсәтелә. Сезгә аны иҗат иткән сәнгать әһеле турында мәгълүмат бирергә һәм портрет исемен әйтергә кирәк.**

**III тур.**

**Бу турда сезгә экранда Муса Җәлил әсәрләренә иллюстрацияләр күрсәтеләчәк. Сезгә әсәрнең исемен атау бурычы куела.**

**IV тур.**

Укучылар, 1 минут эчендә бирелгән бер озын сүздән мөмкин кадәр күбрәк уртаклык исемнәр төзергә кирәк була. Командага һәр сүз саен бер балл куела. Сез 1 минут вакыт эчендә сүзләрне язып жюрига тапшырасыз.

**КАҺАРМАНЛЫК сүзенә кергән хәрефләр белән уртаклык исемнәр ясагыз.**

(Каһарман, карама, кармак, аркан, карак, какы, алка, акыл, арка, алма, кыл, кар, кан, как, кыр, мал, ым).

**IV турның икенче өлешендә** экранда сезгә хаталы итеп язылган сүзтезмәләр тәкъдим ителә. Сез шулардагы хаталарны табып төзәтеп жюрига тапшырасыз. Моңа 1 минур вакыт бирелә.

| | |
|---|---|
| саф хава | саф һава |
| мәсәлә чишү | мәсьәлә чишү |
| шәхәрдә яшәү | шәһәрдә яшәү |

| | |
|---|---|
| китапхәнәгә бару | китапханәгә бару |
| шигыр ятлау | шигырь ятлау |
| көтөлмәгән вакыйга | көтелмәгән вакыйга |
| борыңгы кала | борынгы кала |
| умбиш малай | унбиш малай |
| сүрәт ясау | сурәт ясау |
| хөнәрле кеше | һөнәрле кеше |

**V тур.**

Бу – капитаннар ярышы. Капитаннарга "Тиз җавап" биреме тәкъдим ителә. Муса Җәлил иҗаты буенча гыйбарәләр әйтелә, ул дөрес булса, раслап, әйе дияргә; дөрес булмаса, юк дияргә кирәк була. Җавап бирү өчен капитанга 1 минут вакыт биреләчәк, күпме дөрес җавап биреп өлгерсә, капитан үз командасына шулкадәр балл өсти.

***1 нче мәктәпнең "Таң йолдызлары"командасына***

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муса Җәлил  кызының исеме – Чулпан. | Әйе |
| 2. | Җәлилчеләр оешмасындагы 10 кеше үлемгә хөкем ителә. | Юк, 11 |
| 3. | "Муса" романының авторы –  Нәкый Исәнбәт. | Юк, Шәйхи Маннур |
| 4. | Беренче шигыре 9 яшьтә языла. | Әйе. |
| 5. | "Алтынчәч" операсы беренче мәртәбә 1942 нче елда сәхнәгә куела. | Юк, 1941 нче елда |
| 6. | "Муса абый" повестеның авторы – Әнвәр Давыдов. | Әйе |
| 7. | "Моңлы бер җыр" драмасының авторы – Туфан Миңнуллин. | Әйе |
| 8. | Җәлил исеме белән аталган поселок Татарстанның Актаныш районында урнашкан. | Юк, Сарман районында |

***2 нче мәктәпнең "Маяк" командасына***

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муса Җәлил  1906 нчы елда туган. | Әйе |
| 2. | Муса Җәлилең беренче шигыре Оренбургта языла. | Әйе |
| 3. | Бакчачы бабайның яше 80 дә бугай. | Юк, 90 да. |
| 4. | М.Җәлилгә үлгәннән соң Герой исеме бирелә. | Әйе |
| 5. | "Моңлы бер җыр" драмасының авторы – Нәкый Исәнбәт. | Юк, Т.Миңнуллин |
| 6. | М.Җәлилгә 1957 нче елда Ленин исемендәге | Әйе |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт премиясе бирелә. | |
| 7. | "Хуш, акыллым" шигыре кызы Чулпанга багышланган. | Юк, хатыны Әминәгә |
| 8. | Муса Җәлил 1941 нче елда әсирлеккә төшә. | Юк, 1942 нче елда |

***5 нче мәктәпнең “Чәчәкләр” командасына***

| | | |
|---|---|---|
| 1. | М.Җәлилнең әсирлектәге псевдонимы – Гыйниятов. | Юк, Гомәров |
| 2. | Муса Җәлилнең беренче шигыре «Кечкенә Муса» имзасы белән басылып чыга. | Юк, «Кечкенә Җәлил» |
| 3. | "Җәлил" драмасының авторы – Нәкый Исәнбәт. | Әйе |
| 4. | М.Җәлил оешмасындагы 11 кеше үлемгә хөкем ителә. | Әйе |
| 5. | "Җәлил" драмасының авторы – Туфан Миңнуллин. | Юк, Нәкый Исәнбәт |
| 6. | "Өзелгән җыр эзеннән" әсәренең авторы – Рафаил Мостафин. | Әйе |
| 7. | Җәлил исеме белән аталган поселок Татарстанның Мөслим районында урнашкан. | Юк, Сарман районында |
| 8. | Муса Җәлилнең беренче шигыре Оренбургта чыга торган «Кызыл йолдыз» газетасында басылып чыга. | Әйе |

***6 нчы мәктәпнең “Кызыл ромашка” командасына***

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муса Җәлил 15 нче февральдә туган. | Әйе. |
| 2. | "Сандугач һәм чишмә" әсәренең жанры – поэма. | Юк, баллада |
| 3. | Муса Җәлилең беренче шигыре “Бәхет” дип атала. | Әйе. |
| 4. | М.Җәлилгә үлгәннән соң Г.Тукай премиясе бирелә. | Юк, Ленин премиясе |
| 5. | "Муса" романының авторы – Шәйхи Маннур | Әйе |
| 6. | Муса Җәлил 1943 нче елда әсирлеккә төшә. | Юк, 1942 нче елда |
| 7. | Муса Җәлилнең беренче шигыре «Кечкенә Җәлил» имзасы белән басылып чыга. | Әйе |
| 8. | Казанда Җәлил исемен драма театры йөртә? | Юк, Опера һәм балет театры |

*7 нче мәктәпнең “Хыял” командасына*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муса Җәлил  хатынының исеме – Әминә. | Әйе |
| 2. | М.Җәлилгә 1957 нче елда Ленин исемендәге Дәүләт премиясе бирелә. | Әйе |
| 3. | Бакчачы бабайның яше 90 да бугай. | Әйе. |
| 4. | "Тупчы анты" җыентыгына әдипнең тоткынлык чоры шигырьләре керә. | Юк, әсирлеккә төшкәнче язылган шигырьләре керә. |
| 5. | "Алтынчәч" операсы беренче мәртәбә 1940 нчы елда сәхнәгә куела. | Юк, 1941 нче елда |
| 6. | "Муса абый" повестеның авторы – Әнвәр Нургалиев. | Юк, Әнвәр Давыдов |
| 7. | Казанда Җәлил исемен Опера һәм балет театры йөртә? | Әйе |
| 8. | Муса Җәлилнең беренче шигыре Оренбургта чыга торган «Кызыл коммунист» газетасында басылып чыга. | Юк, “Кызыл йолдыз” газетасында |

*Лесхоз мәктәбенең– “Ромашкалар” командасына*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Муса Җәлил  сугышта Сталинград фронтында катнаша? | Юк, Волхов фронтында |
| 2. | "Тупчы анты" җыентыгына әдипнең сугышка кадәрге чор шигырьләре керә. | Юк, сугыш чорында әсирлеккә төшкәнче язылган шигырьләре керә. |
| 3. | "Алтынчәч" операсы беренче мәртәбә 1940 нчы елда сәхнәгә куела. | Юк, 1941 нче елда |
| 4. | "Кызыл ромашка" әсәренең жанры – поэма. | Юк, шигырь |
| 5. | "Өзелгән җыр эзеннән" әсәренең авторы – Рафаил Мостафин. | Әйе |
| 6. | "Хуш, акыллым" шигыре Әминә Җәлиловага багышланган. | Әйе |
| 7. | Муса Җәлил  сугышта Волхов фронтында була? | Әйе |
| 8. | Муса Җәлилнең әсирлектәге псевдонимы – Гомәров. | Әйе |

**VI тур.** Шигырь сөйләү ярышы.

*(Жюри бәйгегә нәтиҗә ясый. Җиңүче команда билгеләнә. Укытучы кызыклы уен өчен рәхмәт белдерә).*

Әйткәнеңчә, синең җырлар, Муса,
Ил кырында чәчәк аттылар.
Үз илендә алар көч һәм ялкын,
Мәңге сүнмәс яшәү таптылар.